ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы
Регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентына (Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2010 елның 9 июнендәге 973-IV ДС номерлы карары редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 2 (I өлеш); 2005, № 3 (II өлеш), № 10 (II өлеш), № 12 (V өлеш); 2006, № 1, № 10 (I өлеш); 2007, № 10, № 12 (IV өлеш); 2008, № 11 (IV өлеш); 2010, № 6 (III өлеш); 2011, № 3, № 12; 2013, № 5, № 12 (II өлеш); 2014, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); 2015, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); 2016, № 11; 2017, № 7, № 12; 2018, № 12; 2019, № 7 – 8; 2020, № 4; 2021, № 1 – 2, № 12; 2022, № 5 – 6; 2023, № 4) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 16 статьяның 3 өлешендә «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил,» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы Конституция советы Рәисе,» сүзләрен өстәргә;

2) 48 статьяда:

а) 1 өлештә «Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе,» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы Конституция советы әгъзалары,» сүзләрен өстәргә;

б) 2 өлештә «Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе,» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы Конституция советы әгъзалары,» сүзләрен өстәргә;

3) 50 статьяның 4 өлешендә «депутат таләпләрен игълан итү,» сүзләрен «депутат таләпләрен, депутат берләшмәләре гаризаларын игълан итү,» сүзләренә алмаштырырга;

4) 55 статьяның 4 өлешендә «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил,» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы Конституция советы Рәисе,» сүзләрен өстәргә;

5) 62 статьяның 3 өлешендә «Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе,» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы Конституция советы әгъзалары,» сүзләрен өстәргә;

6) 77 статьяның 3 өлешендә «атасының исеме» сүзләреннән соң «(булганда)» сүзен өстәргә;

7) 84 статьяның 1 өлешендәге 2 пунктында «аңлатма язуы» сүзләреннән соң «, шулай ук закон проектын кабул итү кирәклеге турында дәлилле нигезләү» сүзләрен өстәргә;

8) 87 статьяга түбәндәге эчтәлекле 2¹ өлеш өстәргә:

«2¹. Татарстан Республикасы Конституциясен кабул итү, Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы закон проекты бәяләмә бирү өчен Дәүләт Советы Рәисе тарафыннан Татарстан Республикасы Конституция советына җибәрелә.»;

9) 112 статьяның 1 өлешендәге 5 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

10) 156 статьяда «дәүләт тикшереп торуын гамәлгә ашыру өчен» сүзләрен «тышкы дәүләт финанс тикшереп торуын гамәлгә ашыру өчен» сүзләренә алмаштырырга;

11) түбәндәге эчтәлекле 24¹ бүлек өстәргә:

«24¹ бүлек. **Татарстан Республикасы Конституция советы әгъзаларын билгеләп кую**

**158¹ статья**

1. Татарстан Республикасы Конституция советы әгъзалары вазыйфага Дәүләт Советы тарафыннан депутатларның билгеләнгән саныннан күпчелек тавыш белән билгеләп куела.

2. Дәүләт Советына Татарстан Республикасы Конституция советы әгъзаларына бер кандидатны Татарстан Республикасы Рәисе, ике кандидатны Дәүләт Советы Рәисе тәкъдим итә.

3. Татарстан Республикасы Конституция советы әгъзалары вазыйфаларына тәкъдим ителгән кандидатуралар алдан профильле комитет тарафыннан карала.

4. Татарстан Республикасы Конституция советы әгъзасы вазыйфасына билгеләп кую турындагы карар индивидуаль тәртиптә кабул ителә һәм, өстәмә тавыш бирмичә генә, Дәүләт Советы карары белән рәсмиләштерелә.

**158[2] статья**

1. Татарстан Республикасы Конституция советы Рәисе вазыйфага Дәүләт Советы билгеләп куйган Татарстан Республикасы Конституция советы әгъзалары арасыннан Дәүләт Советы тарафыннан Татарстан Республикасы Рәисе тәкъдиме белән билгеләп куела.

2. Татарстан Республикасы Конституция советы Рәисе, әгәр аның өчен депутатларның билгеләнгән саныннан күпчелек тавыш бирелсә, вазыйфага билгеләп куелган дип санала.

3. Татарстан Республикасы Конституция советы Рәисен билгеләп кую турындагы карар, өстәмә тавыш бирмичә генә, Дәүләт Советы карары белән рәсмиләштерелә.

**158[3] статья**

Әгәр Татарстан Республикасы Конституция советы әгъзаларына Татарстан Республикасы Рәисе яисә Дәүләт Советы Рәисе тарафыннан тәкъдим ителгән нинди дә булса кандидат яисә Татарстан Республикасы Конституция советы Рәисе вазыйфасына Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан тәкъдим ителгән кандидат, билгеләп кую өчен таләп ителгән тавышлар саны алмаса, Дәүләт Советына әлеге бүлектә билгеләнгән тәртиптә тиешенчә Татарстан Республикасы Рәисе яисә Дәүләт Советы Рәисе башка кандидатны тәкъдим итә.

12) 173 статьяның 2 өлешендә «атасының исемен» сүзләреннән соң «(булганда)» сүзен өстәргә;

13) түбәндәге эчтәлекле 30[1] бүлек өстәргә:

«30[1] бүлек. **Татарстан Республикасы Конституция советына мөрәҗәгать итү**

**175[1] статья**

1. Дәүләт Советы, аның Президиумы, комитетлар һәм депутатлар Татарстан Республикасы законнарының һәм аларның аерым нигезләмәләренең, Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, башка Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары норматив хокукый актларының, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары норматив хокукый актларының конституциячеллеге яисә конституциячел булмавы турындагы гарызнамә белән, шулай ук Татарстан Республикасы Конституциясе нигезләмәләренә аңлатма бирү турындагы гарызнамә белән Татарстан Республикасы Конституция советына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

2. Дәүләт Советының яисә аның Президиумының гарызнамә белән Татарстан Республикасы Конституция советына мөрәҗәгате турындагы тәкъдим, һәр депутатның фамилиясен, исемен һәм атасының исемен (булганда) күрсәтеп, комитет яисә депутатлар төркеме тарафыннан кертелә.

**175$^{2}$ статья**

Дәүләт Советы, аның Президиумы яисә комитеты тарафыннан Татарстан Республикасы Конституция советына гарызнамә белән мөрәҗәгать турындагы тәкъдимнәрне кертү, карау һәм кабул итү тиешенчә Дәүләт Советы, аның Президиумы, комитеты карарларын кабул итү өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

14) түбәндәге эчтәлекле 189$^{3}$ статья өстәргә:
«**189$^{3}$ статья**

1. Татарстан Республикасы Конституция советы Дәүләт Советына елга бер тапкыр Татарстан Республикасында конституциячел законлылык торышы турында доклад юллый.

2. Доклад Дәүләт Советы утырышында Татарстан Республикасы Конституция советы Рәисе тарафыннан тәкъдим ителә.

3. Татарстан Республикасы Конституция советының еллык докладын карау нәтиҗәләре буенча Дәүләт Советы үз компетенциясе чикләрендә Татарстан Республикасында конституциячел законлылыкны ныгыту чараларын кабул итә, бу турыда Татарстан Республикасында Конституция советына хәбәр ителә.»;

15) 190$^{2}$ статьяның 2 өлешендә «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының эшчәнлеге турында» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеге нәтиҗәләре турында» сүзләренә алмаштырырга;

16) 191 статьяда:

а) $2^{1}$ пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $14^{2}$ пункт өстәргә:

«$14^{2}$) Татарстан Республикасы Конституция советы Рәисе һәм Татарстан Республикасы Конституция советы әгъзалары вазыйфасына билгеләп кую һәм аларның вәкаләтләрен туктату турында;»;

в) түбәндәге эчтәлекле $15^{1}$ пункт өстәргә:

«$15^{1}$) Татарстан Республикасы Конституция советына мөрәҗәгатьләр кабул итү турында;».

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы Ю.З. Камалтынов

Казан шәһәре,
2024 елның 29 марты
№ 2414-VI ДС